**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ИВАШКИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул.Центральная, д.1а, с.Ивашкино, 423113

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ИВАШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

Үзек урамы, 1а йорт, Ивашкино авылы, 423113

тел./факс (84396) 3-82-19 email: Iva.Cmn2@tatar.ru

26 октябрь 2020 ел № 12

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Ивашкино авыл җирлеге Советы
карары

**ҖИР САЛЫМЫ ТУРЫНДА**

1 Статья. Гомуми нигезләмәләр

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә әлеге карар белән Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри түләнергә тиешле җир салымы билгеләнә һәм гамәлгә кертелә.

2 Статья. Салым ставкалары

Салым ставкалары кадастр бәясеннән түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

1) авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә торак пунктларда авыл хуҗалыгы кулланылышы зоналары составындагы һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланыла торган җирләргә карата 0,3% ;

2) 0,3% торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектларына керми торган җир кишәрлегенә хокукы өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата (эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган, индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш);

3) оборона, куркынычсызлык һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештә чикләнгән җир кишәрлекләренә карата 0,3%;

4) эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки яшелчәчелек өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләренә карата 0,15%;

5) башка җир кишәрлекләренә карата 1,5%.

3 Статья. Салым ташламалары

Салым салудан азат итү:

1) Бөек Ватан сугышында катнашучыларны, шулай ук законнар белән Бөек Ватан сугышында катнашучыларның социаль гарантияләре һәм ташламалары каралган гражданнарны, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, индивидуаль торак төзелеше, бакчачылык, яшелчәчелек һәм терлекчелек өчен бирелгән җир кишәрлекләренә карата;

2) оешмалар һәм учреждениеләр гражданнар күмелгән җир кишәрлекләренә карата;

3) муниципаль учреждениеләр мәйданнар, урамнар, юллар, автомобиль юллары, скверлар, бульварлар, шоссе, мәйданнар, су объектлары, пляжлар, су алу скважиналары, үләт базлары, каты көнкүреш калдыклары полигоннары биләгән гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләренә карата.

Салым ташламасын билгеләргә:

Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм муниципаль берәмлек бюджетыннан финанслана торган автоном, бюджет учреждениеләре, хакимият органнары һәм идарә органнарының җир кишәрлекләренә карата 2 статьяның 5 пункты белән билгеләнгән ставкасының 1/10 өлеше (0,15%) күләмендә.

2 статьяның 5 пункты белән билгеләнгән ставканың 1/30 күләмендә (0,05%) 1-3 категорияле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү һәм файдалануга бирү өчен бирелә торган җир кишәрлекләренә карата.

4 Статья. Хисап чоры

Салым түләүче оешмалар өчен хисап чоры дип календарь елның беренче кварталы, икенче кварталы, өченче кварталы танылa. Календарь елы салым чоры дип танылa.

5 Статья. Салым түләү тәртибе һәм сроклары

Түләнергә тиешле салым суммасы турында салым белдерүе салым түләүчегә Россия Федерациясе Салым кодексының 52 статьясында билгеләнгән сроктан да соңга калмыйча тапшырыла.

6 Статья. Салым түләүчеләр тарафыннан салым салу базасын киметү хокукын раслый торган документларны тапшыру тәртибе һәм сроклары

Салым түләүчеләр - салым ташламалары хокукына ия физик затлар, шул исәптән салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым тотып калуы рәвешендә, салым органына үз теләге белән салым ташламасын бирү турында гариза тапшыралар, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документлар тапшырырга хокуклы. Салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслау РФ Салым кодексының 361.1 статьясындагы 3 пунктында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

7 Статья. Әлеге карарның үз көченә керүе

1. Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге Советының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

2013 елның 07 ноябрендәге 66 номерлы "Җир салымы турында";

2014 елның 12 ноябрендәге 91 номерлы "Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге Советының 2013 елның 07 ноябрендәге 66 номерлы "Җир салымы турында" карарына үзгәрешләр кертү турында".

2015 елның 5 маендагы 115 номерлы "Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге Советының 2013 елның 07 ноябрендәге 66 номерлы "Җир салымы турында" карарына үзгәрешләр кертү турында".

2018 елның 12 мартындагы 78 номерлы "Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге Советының 2013 елның 07 ноябрендәге 66 номерлы "Җир салымы турында" карарына үзгәрешләр кертү турында".

2019 елның 28 октябрендәге 147 номерлы "Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге Советының 2013 елның 07 ноябрендәге 66 номерлы "Җир салымы турында" карарына үзгәрешләр кертү турында".

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да иртәрәк түгел.

3. Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуда җаваплылыкны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Ивашкино авыл җирлеге
Башлыгы, Совет рәисе Н.А. Емельянов